**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ТУЕМБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТУЕМБАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422114, Республика Татарстан, Кукморский район,
с. Туембаш, ул. Ленина, д.68
тел.: 8(84364) 31-5-44
эл. почта: Tuem.Kuk@tatar.ru

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Туембаш авыл җирлеге Советы

**КАРАР**

«16» декабрь 2025 ел. № 12

Туембаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 01 июнендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларга, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Березняк авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Туембаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 01 июнендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) (Туембаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 7 ноябрендәге 28 номерлы, 2020 елның 21 декабрендәге 13 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 39 номерлы, 2024 елның 11 июнендәге 19 номерлы, 2024 елның 31 июлендагы 21 номерлы 2024 елның 29 августындагы 32 номерлы, 2024 елның 03 декабрендәге 43 номерлы, 2025 елның 23 июнендагы 18 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 2 бүлекнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Муниципаль берәмлек башлыгына айлык акчалата түләү түбәндәгедән артмаган күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата түләүнең күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | Уникенче төркем (халык саны 1,5 мең кешегә кадәр) |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 23 201,0 |

б) 3.1 пунктның беренче абзацында «15 389» санын «16 928» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Туембаш авыл җирлеге башлыгы И.Ф. Гарипов